АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2020 п.г.т. Алексеевское № 308

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2019 елның 18 октябрендәге 269 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

20 маддәнең 14 өлешендә «акчаларны исәпкә алу» сүзләрен төшереп калдырырга;

46 маддәнең 2 пунктында «Федераль казначылык органнары счетларыннан» сүзләрен «исәпкә алу һәм кертемнәрне бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм кире кайтару өчен казначылык счетларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

47 маддәнең 3 пунктында «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алга таба - күрсәтмә)» сүзләренә алмаштырырга;

47 маддәнең 5 пунктында «түләү документларын» сүзләрен «күрсәтмәләрен» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы Советы бинасында, ТР, Алексеевск районы, Алексеевск штб., Совет мәйданы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендта урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс мәсьәләләре һәм икътисадый үсеш буенча Алексеевск муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы башлыгы вазыйфаларын башкаручы, Совет рәисе** **Г.В. Белова**